# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Казан шәһәре буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары
чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга 1-7 нче кушымталар нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 16 июне
№ 27-ТРЗ

"Татарстан Республикасы Казан шәһәре буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы

### 1 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районы буенча җәмәгать судьясының 1 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Казан шәһәре Авиатөзелеш районының көньяк чигендә Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына бүлеп бирелгән полоса һәм Восход урамы кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көнбатышка таба Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Мәскәү районы белән административ чиге буйлап, Мәскәү – Екатеринбург тимер юлындагы төп юлның контакт челтәренең төньяк терәге буйлап Теплично-Комбинатская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары төньякка борыла һәм, уң якта урнашкан "Татэнерго" ачык акционер җәмгыятенең сәнәгать зонасы территориясен кертеп, Теплично-Комбинатская урамы буйлап Тэцевская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан "Казан вертолет заводы" ачык акционер җәмгыятенең сәнәгать зонасы территориясен кертеп, Тэцевская урамының күчәр сызыгы буйлап көнбатышка таба Гудованцев урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Гудованцев урамының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба, шәһәр кырыена кадәр бара, алга таба, Гудованцев урамын дәвам итеп, шул ук юнәлештә Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Мәскәү районы белән административ чиге буйлап, "Сирень", "КМПО-5" бакчачылык ширкәтләре территорияләрен кертеп, шушы бакчачылык ширкәтләре һәм урман утыртмалары территорияләренең көнбатыш чикләре буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары көнчыгыш юнәлештә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Зеленодольск һәм Биектау муниципаль районнары белән чиге буйлап Озерный совхозы – М-7 федераль трассасы автомобиль юлы чишелешенә (М-7 федераль трассасына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге белән Казан – Озерный автомобиль юлы кисешкән җирдә) кадәр бара, аннары көньякка борыла һәм Казан – Озерный автомобиль юлының көнбатыш ягы буйлап "КМПО-14" бакчачылык ширкәте чигенең төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, урман утыртмалары һәм "Бакча-8" бакчачылык ширкәте территорияләрен кертеп, көньяк юнәлештә "КМПО-14", "КМПО-8", "КАПО-10" һәм "Элекон-2" бакчачылык ширкәтләре чикләре буйлап

грунт юл буенча "Төньяк" микрорайоны кырыена кадәр бара, алга таба көнбатышка таба торак пункт кырые буйлап уза торган грунт юл буенча Краснодонская урамына кадәр бара, аннары көньякка борыла һәм, так якта урнашкан йортларны кертеп, Краснодонская урамының күчәр сызыгы буйлап Беломорская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, көнчыгышка таба Беломорская урамының күчәр сызыгы буйлап Зур Армавир урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Зур Армавир урамының күчәр сызыгы буйлап Зур Армавир урамындагы 1 нче йорт янында Ульяна Громова урамы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, аннары 80 метр шул ук юнәлештә Обнорский урамындагы 24 нче йортның көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан гаражларны һәм бакчачылык ширкәте территориясен кертеп, Обнорский урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба Станиславский урамындагы 30а йорт янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары көньякка борыла һәм "Ветеран" бакчачылык ширкәтенең көнчыгыш чиге буйлап Белинский урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Белинский урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба бара, Белинский урамындагы 11 нче йортның төньяк-көнчыгыш почмагы янында көньякка борыла һәм Белинский урамындагы икенче дәрәҗәдәге юлның күчәр сызыгы буйлап Тэцевская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, уң яктагы сәнәгать зонасы территориясен кертеп, Тэцевская урамының күчәр сызыгы буйлап 140 метр көнчыгышка таба Восход урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары Восход урамының күчәр сызыгы буйлап Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Мәскәү районы белән административ чигендә урнашкан Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкән ноктага кадәр бара.

**2 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районы буенча җәмәгать судьясының 2 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Төньяк Полюс һәм Челюскин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, Төньяк Полюс урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба Яңа Каравай урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Яңа Каравай урамының күчәр сызыгы буйлап Пржевальский урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, көнчыгышка таба Пржевальский урамының күчәр сызыгы буйлап Камчатка һәм Циолковский урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба Камчатка урамы буйлап төньякка таба "КАПО-5" бакчачылык ширкәте территориясе кырыеннан Шоссе урамы (Борисоглебский торак пункты) белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, сул якта урнашкан "КАПО-14" бакчачылык ширкәте һәм Борисоглебский торак пункты территорияләрен кертеп, көнчыгыш юнәлештә "С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе" ачык акционер җәмгыятенең төньяк чиге кырыеннан Казансу елгасы

акваториясендә урнашкан Казан шәһәре Совет районы административ чиге белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, Крутушка, Щербаково, Кадышево, Зәңгәр Күл торак пунктлары территорияләрен кертеп, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Мәскәү районы белән административ чиге буйлап төньякка таба Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең төньяк чиге белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көнбатыш юнәлештә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Биектау муниципаль районы белән чиге буйлап Озерный совхозы – М-7 федераль трассасы автомобиль юлы чишелешенә (М-7 федераль трассасына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге белән Казан – Озерный автомобиль юлы кисешкән җирдә) кадәр уза, аннары көньякка борыла һәм Казан – Озерный автомобиль юлының көнбатыш ягы буйлап "КМПО-14" бакчачылык ширкәтенең төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә урман утыртмалары һәм "Бакча-8" бакчачылык ширкәте территориясе кырыеннан "КМПО-14", "КМПО-8", "КАПО-10" һәм "Элекон-2" бакчачылык ширкәтләренең көнбатыш чикләре буйлап "Төньяк" микрорайоны кырыена кадәр бара, алга таба торак пункт кырые буйлап уза торган грунт юл буенча көнбатышка таба Краснодонская урамына кадәр бара, аннары көньякка борыла һәм, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Краснодонская урамының күчәр сызыгы буйлап Беломорская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Беломорская урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба Зур Армавир урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Зур Армавир урамының күчәр сызыгы буйлап Люба Шевцова урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Люба Шевцова урамының күчәр сызыгы буйлап Побежимов урамындагы 59 нчы йортның көньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба, Побежимов урамындагы 57, 55, 53 нче йортларны кертеп, көньяк-көнчыгышка таба Побежимов урамындагы 57, 55, 53 нче йортлар белән 57а, 55а йортлар арасындагы тыкрык буйлап Челюскин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары төньякка таба Челюскин урамының күчәр сызыгы буйлап Побежимов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Побежимов урамының күчәр сызыгы буйлап Караганда урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, төньякка таба Караганда урамының күчәр сызыгы буйлап Максимов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көньяк-көнчыгышка таба Максимов урамының күчәр сызыгы буйлап Челюскин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, төньяк-көнчыгышка таба Челюскин урамының күчәр сызыгы буйлап Төньяк Полюс урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза.

**3 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районы буенча җәмәгать судьясының 3 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Максимов һәм Челюскин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньяк-көнчыгышка таба Максимов урамының күчәр сызыгы

буйлап 2 нче Ленинград урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба 2 нче Ленинград урамының күчәр сызыгы буйлап Побежимов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньяк-көнчыгышка таба Побежимов урамының күчәр сызыгы буйлап Лукин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Лукин урамы күчәре буйлап Олег Кошевой урамындагы 2б йортның төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан трамвай юллары белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары көнчыгышка таба борыла һәм, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Олег Кошевой урамының күчәр сызыгы буйлап Олег Кошевой урамындагы 20 нче йорт янында Дементьев урамы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары, уң якта урнашкан "Крылья Советов" мәдәният һәм ял паркы һәм "Рубин" стадионы территорияләрен кертеп, көньяк-көнбатышка таба Дементьев урамының күчәр сызыгы буйлап Дементьев урамындагы 1в йортның төньяк-көнбатыш почмагы янында Копылов, Дементьев һәм Тэцевская урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба көньякка борыла һәм Копылов урамының күчәр сызыгы буйлап Копылов, Декабристлар урамнары һәм Ибраһимов проспекты кисешкән җирдә тимер юл күперенең көнчыгыш терәге янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Мәскәү – Екатеринбург тимер юлындагы төп юлның контакт челтәренең төньяк терәге буйлап Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Мәскәү районы белән административ чиге буйлап Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына бүлеп бирелгән полоса Восход урамы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп, төньякка таба Восход урамы буйлап Тэцевская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, уң якта урнашкан "КМПО-1" бакчачылык ширкәте территориясен кертеп, Тэцевская урамының күчәр сызыгы буйлап көнбатышка таба Белинский урамындагы икенче дәрәҗәдәге юл белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Белинский урамындагы икенче дәрәҗәдәге юлның күчәр сызыгы буйлап Белинский урамындагы 11 нче йортның төньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары көнбатышка борыла һәм, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Белинский урамының күчәр сызыгы буйлап "Ветеран" бакчачылык ширкәтенең көнчыгыш чигенә кадәр уза, алга таба төньяк юнәлештә бакчачылык ширкәте чиге буйлап Станиславский урамындагы 30а йорт янында Обнорский урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Обнорский урамының күчәр сызыгы буйлап Обнорский урамындагы 26 нчы йортның көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары төньякка борыла һәм Зур Армавир урамындагы 1 нче йортка кадәр туп-туры 80 метр уза, аннары Зур Армавир урамының күчәр сызыгы буйлап Люба Шевцова урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Люба Шевцова урамының күчәр сызыгы буйлап Побежимов урамындагы 59 нчы йортның көньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба, Побежимов урамындагы 57а, 55а йортларны кертеп, көньяк-көнчыгышка таба Побежимов урамындагы 57, 55, 53 нче йортлар белән 57а, 55а йортлар арасындагы тыкрык буйлап Челюскин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньякка

таба Челюскин урамының күчәр сызыгы буйлап Максимов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр бара.

**4 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районы буенча җәмәгать судьясының 4 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Побежимов һәм Челюскин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньяк-көнбатышка таба Побежимов урамының күчәр сызыгы буйлап Караганда урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньякка таба Караганда урамының күчәр сызыгы буйлап Максимов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньяк-көнчыгышка таба Максимов урамының күчәр сызыгы буйлап Челюскин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньяк-көнчыгышка таба Челюскин урамының күчәр сызыгы буйлап Төньяк Полюс урамының күчәр сызыгына кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнчыгышка таба Төньяк Полюс урамының күчәр сызыгы буйлап Яңа Каравай урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Яңа Каравай урамының күчәр сызыгы буйлап Пржевальский урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнчыгышка таба Пржевальский урамының күчәр сызыгы буйлап Лукин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньяк юнәлештә Лукин урамының күчәр сызыгы буйлап Побежимов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньяк-көнбатышка таба Побежимов урамының күчәр сызыгы буйлап Ленинград урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньякка таба 2 нче Ленинград урамының күчәр сызыгы буйлап Максимов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньяк-көнбатышка таба Максимов урамының күчәр сызыгы буйлап Челюскин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Челюскин урамының күчәр сызыгы буйлап Побежимов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза.

**5 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районы буенча җәмәгать судьясының 5 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Пржевальский һәм Лукин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнчыгышка таба Пржевальский урамының күчәр сызыгы буйлап Камчатка һәм Циолковский урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба төньякка таба "КАПО-5" бакчачылык ширкәте территориясе кырыеннан Камчатка урамы буйлап Шоссе урамы (Борисоглебский торак пункты)

белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, "С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе" ачык акционер җәмгыяте территориясен кертеп, көнчыгыш юнәлештә "КАПО-14" бакчачылык ширкәте һәм Борисоглебский торак пункты территориясе кырыеннан "С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе" ачык акционер җәмгыяте территориясенең төньяк чиге буйлап Казансу елгасы акваториясендә урнашкан Казан шәһәре Совет районының административ чиге белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк юнәлештә Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Совет районы белән административ чиге буенча Казансу елгасы үзәне буйлап агым уңаена аска таба Казансу елгасы аша тимер юл күперенең уртасында Казан шәһәренең Авиатөзелеш, Совет һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Яңа Савин районы белән административ чиге буенча, Мәскәү – Екатеринбург тимер юлындагы төп юлның контакт челтәренең төньяк терәге буйлап Копылов, Декабристлар урамнары һәм Ибраһимов проспекты чикләре тоташкан урында тимер юл күперенең көнчыгыш терәге янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан территорияне кертеп, төньякка таба Копылов урамының күчәр сызыгы буйлап Копылов, Тэцевская һәм Дементьев урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба көнчыгышка борыла һәм, уң якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп, Дементьев урамының күчәр сызыгы буйлап Олег Кошевой урамындагы 20 нче йортның төньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба көнбатышка борыла һәм, так якта урнашкан йортларны кертеп, Олег Кошевой урамының күчәр сызыгы буйлап Олег Кошевой урамындагы 2б йортның төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан трамвай юллары белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары төньякка борыла һәм, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Лукин урамының күчәр сызыгы буйлап Пржевальский урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

"Татарстан Республикасы Казан шәһәре буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районы буенча җәмәгать судьясының 1 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Кремль дамбасы янында Куйбышев сусаклагычы (Казансу елгасы) акваториясендә урнашкан Казан шәһәренең Киров, Яңа Савин һәм Вахитов районнарының административ чикләре кисешкән ноктадан алып туры сызык буйлап Кремль дамбасындагы автомобиль күперенең төньяк терәгенә кадәр уза, алга таба автомобиль күперенең күчәр сызыгы буйлап уза һәм Хрущевский Вал, Ярминкә һәм Казансу Яры урамнары кисешкән ноктага чыга, Казан Кремле диварлары кырыендагы автомобиль юлы буйлап уза һәм Профсоюз урамына чыга, так якта урнашкан йортларны кертеп, Профсоюз урамының күчәр сызыгы буйлап Пушкин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап өскә таба бара, Щапов урамы белән кисешкән җиргә кадәр килеп җитә, так якта урнашкан йортларны кертеп, Щапов урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Мөштәри урамы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларын кертеп, төньякка таба Мөштәри урамы буйлап Карл Маркс урамына кадәр барып җитә, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Карл Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнбатышка таба уза, Ирек мәйданы районында Пушкин урамына чыга, аннары, Ирек мәйданын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бинасын кертеп, Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап уза һәм Солтан Галиев мәйданына кадәр барып җитә, алга таба, "Казан" милли-мәдәни үзәге (алга таба – "Казан" ММҮ) бинасын кертеп, Пушкин урамыннан туры сызык буйлап Солтан Галиев мәйданын кисеп үтә һәм "Казан" ММҮ янында Куйбышев сусаклагычы (Казансу елгасы) акваториясендә урнашкан Казан шәһәренең Яңа Савин һәм Вахитов районнарының административ чикләре кисешкән ноктага чыга, әлеге ноктадан алып Кремль дамбасы янында Куйбышев сусаклагычы (Казансу елгасы) акваториясендә урнашкан Казан шәһәренең Киров, Яңа Савин һәм Вахитов районнарының административ чикләре кисешкән ноктага кадәр Казансу елгасы акваториясе буйлап агым уңаена аска таба Казансу Яры урамы буйлап уза.

**2 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районы буенча җәмәгать судьясының 2 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге "Казан" ММҮ янында Куйбышев сусаклагычы (Казансу елгасы) акваториясендә урнашкан Казан шәһәренең Яңа Савин һәм Вахитов районнарының административ чикләре кисешкән ноктадан алып Солтан Галиев мәйданына уза, Солтан Галиев мәйданын кисеп үтә һәм Пушкин урамына чыга, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Ирек мәйданы районында Карл Маркс урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, так якта урнашкан йортларны кертеп, Карл Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Мөштәри урамына чыга, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Мөштәри урамының күчәр сызыгы буйлап бара, Щапов урамы белән кисешкән ноктага кадәр барып җитә, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Щапов урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Пушкин урамына чыга, җөп якта урнашкан йортларны һәм Тукай мәйданын кертеп, Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Петербург урамына чыга, так якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәр сызыгы буйлап Луковский урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Луковский урамының күчәр сызыгы буйлап бара, Роща Фрунзе урамына чыга, так якта урнашкан йортларны кертеп, Роща Фрунзе урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Айвазовский һәм Яшел урамнары кисешү ноктасына кадәр барып җитә, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Айвазовский урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Волков урамы белән кисешкән җиргә кадәр килеп җитә, так якта урнашкан йортларны кертеп, Волков урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Курашов урамы белән кисешкән җиргә кадәр барып җитә, так якта урнашкан йортларны кертеп, Курашов урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Карл Маркс урамына кадәр барып җитә, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Карл Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап бара, Николай Ершов урамына күчә, так якта урнашкан йортларны кертеп, Николай Ершов урамының күчәр сызыгы буйлап бара, Мәскәү – Пермь тимер юлы өстендәге автомобиль күпере районында Казан шәһәре Совет районының административ чиге белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба Казан шәһәре Вахитов районының Совет районы белән административ чиге буйлап Мәскәү – Пермь тимер юлы буенча "Немец Швейцариясе" урман паркына кадәр барып җитә, тимер юлга перпендикуляр рәвештә туры сызык буйлап шушы урман паркы аша чыга һәм Казансу елгасы акваториясендә Казан шәһәренең Яңа Савин, Вахитов һәм Совет районнары административ чикләре кисешкән ноктага чыга, алга таба Казан шәһәре Вахитов районының Яңа Савин районы белән административ чиге буенча Казансу елгасы акваториясе буйлап "Казан" ММҮ янында Куйбышев сусаклагычы (Казансу елгасы) акваториясендә урнашкан Казан шәһәре Яңа Савин һәм Вахитов районнарының административ чикләре кисешкән ноктага кадәр уза.

**3 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районы буенча җәмәгать судьясының 3 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Кремль дамбасы янында Куйбышев сусаклагычы (Казансу елгасы) акваториясендә Казан шәһәренең Киров, Яңа Савин һәм Вахитов районнарының административ чикләре кисешкән ноктадан алып туры сызык буйлап Кремль дамбасындагы автомобиль күперенең төньяк терәгенә кадәр бара, алга таба автомобиль күперенең күчәр сызыгы буйлап уза һәм Хрущевский Вал, Ярминкә һәм Казансу Яры урамнары кисешкән ноктага чыга, Казан Кремле диварлары кырыендагы автомобиль юлы буйлап уза һәм Профсоюз урамына чыга, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Профсоюз урамының күчәр сызыгы буйлап Пушкин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Татарстан урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Завод урамына борыла, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәр сызыгы буйлап уза, алга таба Галиәсгар Камал урамына борыла, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Галиәсгар Камал урамының күчәр сызыгы буйлап уза, "Локомотив" кызыну урыны районында Куйбышев сусаклагычы яр буена чыга, алга таба туры сызык буйлап көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясендә Казан шәһәре Вахитов һәм Киров районнарының административ чикләре Югары Ослан муниципаль районы чиге белән тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр бара, алга таба шушы ноктадан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Казан шәһәре Вахитов районының Киров районы белән административ чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба Кремль дамбасы янында Куйбышев сусаклагычы (Казансу елгасы) акваториясендә урнашкан Казан шәһәренең Киров, Яңа Савин һәм Вахитов районнарының административ чикләре кисешкән ноктага кадәр бара.

**4 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районы буенча җәмәгать судьясының 4 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Куйбышев сусаклагычы акваториясендә Казан шәһәре Киров һәм Вахитов районнарының административ чикләре Югары Ослан муниципаль районы чиге белән тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасыннан алып Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең чиге буенча көньяк-көнбатыш юнәлештә Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Казан елга порты акваториясендә урнашкан яклау молының көньяк-көнбатыш очына кадәр уза, алга таба шушы ноктадан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап көнчыгышка таба бара һәм Меховщиклар урамы районында елга ярына чыга, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, 86 нчы йорттан алып Меховщиклар урамының күчәр сызыгы буйлап уза, алга таба Казан шәһәре Вахитов районының Идел буе районы белән административ чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба Яңа Татар зираты кырыеннан

сәнәгать билгеләнешендәге тимер юл тармагына кадәр, аннары тимер юл тармагы буйлап төньякка таба Әхтәмов урамына кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә башта Кәрим Тинчурин скверы белән "Электрон" стадионы арасында Казан шәһәре Вахитов районының Идел буе районы белән административ чиге буйлап уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Әхтәмов урамының күчәр сызыгы буйлап, Кәрим Тинчурин урамындагы 21 нче йорттан алып Сара Садыйкова урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Сара Садыйкова урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Габдулла Тукай урамына күчеп һәм Вахитов мәйданына чыгып, көньякка таба бара, аннары Эсперанто урамының күчәр сызыгы буйлап Түбән Кабан күленә кадәр уза, алга таба Түбән Кабан күле яры буйлап Марсель Сәлимҗанов урамына кадәр уза, Марсель Сәлимҗанов урамы буйлап Татарстан урамына чыга, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Татарстан урамының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнчыгыш юнәлештә уза, Завод урамына борыла, так якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәр сызыгы буйлап уза, алга таба Галиәсгар Камал урамына борыла, так якта урнашкан йортларны кертеп, Галиәсгар Камал урамының күчәр сызыгы буйлап уза, "Локомотив" кызыну урыны районында Куйбышев сусаклагычы яр буена чыга, алга таба туры сызык буйлап көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясендә Казан шәһәре Киров һәм Вахитов районнарының административ чикләре Югары Ослан муниципаль районы чиге белән тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза.

**5 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районы буенча җәмәгать судьясының 5 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Мәскәү – Пермь тимер юлы өстендәге автомобиль күпере районында Николай Ершов урамының күчәр сызыгының Казан шәһәре Совет районының административ чиге белән кисешкән ноктадан алып уза, алга таба, төньяк-көнбатыш юнәлештә, Карл Маркс урамына күчеп, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Николай Ершов урамы күчәр сызыгы буйлап Курашов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Курашов урамының күчәр сызыгы буйлап Волков урамына кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Волков урамының күчәр сызыгы буйлап уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Яшел урамының күчәр сызыгы буйлап бара, Калинин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Калинин урамының күчәр сызыгы буйлап Вишневский урамына кадәр барып җитә, Вишневский урамын кисеп үтә һәм, так якта урнашкан йортларны кертеп, Әмирхан Еники урамының күчәр сызыгы буйлап уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Товарищеская урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Пугачев урамы белән кисешкән җиргә кадәр килеп җитә, так якта урнашкан йортларны кертеп, Пугачев урамының күчәр сызыгы буйлап уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Мәсгут Латыйпов урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Әбҗәлилов урамы районында Мәскәү – Пермь

тимер юлына чыга, аннары Мәскәү – Пермь тимер юлы буйлап Казан шәһәре Вахитов районының Совет районы белән административ чиге буенча Николай Ершов урамы күчәр сызыгының Мәскәү – Пермь тимер юлы өстендәге автомобиль күпере районында Казан шәһәре Совет районының административ чиге белән кисешкән ноктага кадәр уза.

**6 нчы суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районы буенча җәмәгать судьясының 6 нчы суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Мәскәү – Пермь тимер юлында Әбҗәлилов урамы районында Мәсгут Латыйпов урамының күчәр сызыгы һәм Казан шәһәре Совет районының административ чиге кисешкән ноктадан алып Мәскәү – Пермь тимер юлы буйлап көньяк-көнчыгышка таба Казан шәһәре Вахитов районының Совет районы белән административ чиге буенча Подкаменная урамына кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Казан шәһәре Идел буе районының административ чиге буенча Подкаменная урамының күчәр сызыгы буйлап бара, аннары Агрономия урамына күчә, так якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәр сызыгы буйлап уза, Эсперанто урамына кадәр барып җитә, Вишневский урамына күчә торган Эсперанто урамының күчәр сызыгы буйлап күтәрелә, так якта урнашкан йортларны кертеп, Вишневский урамы буйлап уза һәм Әмирхан Еники урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәр сызыгы буйлап уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Товарищеская урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Пугачев урамы белән кисешкән җиргә кадәр барып җитә, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Пугачев урамының күчәр сызыгы буйлап уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Мәсгут Латыйпов урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Әбҗәлилов урамы районында Мәскәү – Пермь тимер юлында Мәсгут Латыйпов урамының күчәр сызыгы һәм Казан шәһәре Совет районының административ чиге кисешкән ноктага чыга.

**7 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районы буенча җәмәгать судьясының 7 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Тукай мәйданы районында Петербург һәм Пушкин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән ноктадан алып, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап Марсель Сәлимҗанов урамына кадәр уза, Марсель Сәлимҗанов урамы буйлап Түбән Кабан күле ярына чыга, алга таба Түбән Кабан күле яр буе буйлап Вахитов мәйданы районында Казан шәһәре Идел буе районы административ чигенең Эсперанто урамы белән кисешү ноктасына кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Эсперанто һәм Вишневский урамнарының күчәр сызыгы буйлап Калинин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Калинин урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Яшел урамына барып җитә, так якта урнашкан

йортларны кертеп, Яшел урамының күчәр сызыгы буйлап уза, Роща Фрунзе урамына кадәр барып җитә, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Роща Фрунзе урамының күчәр сызыгы буйлап Луковский урамына кадәр уза, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Луковский урамының күчәр сызыгы буйлап Петербург урамы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Петербург урамының күчәр сызыгы буйлап Тукай мәйданы районында Петербург һәм Пушкин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр бара.

"Татарстан Республикасы Казан шәһәре буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы

### 1 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров районы буенча җәмәгать судьясының 1 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Лушников һәм 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, Лушников урамының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнбатышка таба Коммунарлар, Дружина һәм Дежнев урамнары кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Дежнев урамының күчәр сызыгы буйлап Аркылы Базар урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Аркылы Базар урамының күчәр сызыгы буйлап Беренче Май урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Беренче Май урамының күчәр сызыгы буйлап "Казан дары заводы" федераль казна предприятиесе территориясенең көнчыгыш чигенә кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба "Казан дары заводы" федераль казна предприятиесе территориясен аның көньяк, көнбатыш, төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап әйләнеп уза һәм Богатырев урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньяк-көнчыгышка таба Богатырев урамының күчәр сызыгы буйлап Степан Халтурин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньякка таба Степан Халтурин урамының күчәр сызыгы буйлап Фрунзе, Степан Халтурин һәм Краснококшайская урамнары тоташкан урында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, төньяк-көнбатышка таба Фрунзе урамының күчәр сызыгы буйлап Коләхмәтов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньяк-көнчыгышка таба Коләхмәтов урамының күчәр сызыгы буйлап Коләхмәтов, Сабан һәм Батыршин урамнары кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньяк-көнчыгышка таба Батыршин урамының күчәр сызыгы буйлап Галимҗан Баруди урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Галимҗан Баруди урамының күчәр сызыгы

буйлап Серов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Серов урамының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм Серов, Зур Крыловка, Ленская һәм Тверь урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба Ленская урамы кырыеннан төньяк-көнчыгышка таба 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамының күчәр сызыгы буйлап Лушников урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза.

**2 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров районы буенча җәмәгать судьясының 2 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Коләхмәтов, Сабан һәм Батыршин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Коләхмәтов урамының күчәр сызыгы буйлап Фрунзе урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көньяк-көнчыгышка таба Фрунзе урамының күчәр сызыгы буйлап Фрунзе, Степан Халтурин һәм Краснококшайская урамнары тоташкан урында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Степан Халтурин урамының күчәр сызыгы буйлап Богатырев урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Богатырев урамының күчәр сызыгы буйлап "Казан дары заводы" федераль казна предприятиесе территориясенең көнчыгыш чигенә кадәр бара, аннары, уң якта урнашкан территорияне кертеп, төньяк-көнбатышка таба "Казан дары заводы" федераль казна предприятиесенең көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап "Казан дары заводы" федераль казна предприятиесе территориясе коймасының төньяк-көнбатыш почмагында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан территорияне кертеп, 360 метр төньяк-көнбатышка таба Калинин торак пунктының төньяк-көнчыгыш кырые буйлап тимер юл чишелеше янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары, уң якта урнашкан урман утыртмалары территориясен кертеп, төньяк-көнчыгыш юнәлештә Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап Васильченко урамындагы автомобиль күперенә кадәр бара, алга таба көньякка борыла һәм Казан шәһәре Киров районының Мәскәү районы белән административ чиге буйлап, йонны беренчел эшкәртү фабрикасы складлары территориясенең көнчыгыш чиге буйлап Горький шоссесындагы 26 нчы йортның төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка борыла һәм "Тасма-Холдинг" ачык акционер җәмгыятенең сәнәгать зонасы коймасы янында урнашкан бакчаларның көньяк чикләре буйлап Восстание урамына кадәр бара, аннары "Дары" зиратының төньяк чиге районында Восстание урамын кисеп үтә, алга таба "Дары" зиратының төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап Сабан урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Сабан урамының

күчәр сызыгы буйлап Сабан, Коләхмәтов һәм Батыршин урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

**3 нче суд участогы**

